| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.06.2023 г.Лениногорск № 33

2016 елның 7 декабрендәге 106 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы турында» карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 06 февралендәге 12-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.2016 елның 7 декабрендәге 106 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы турында» карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертергә (1нче кушымта).

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3.»Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2016 елның 7 декабрендәге 106 номерлы Лениногорск муниципаль районы Советы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә юлларга.

4.«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2016 елның 7 декабрендәге 106 номерлы Лениногорск муниципаль районы Советы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы «муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү хакында» карарын Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләрне дәүләт теркәвеннән соң Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль
районы башлыгы,
Советы рәисе Р.Г.Хөсәенов

Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 01 июнендәге 33 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставында үзгәрешләр**

1) 27 статьяда:

1 өлешнең 7.2 пунктында «Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

1 өлештә 7.4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 36 статьяда:

1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 11.2 пункт өстәргә:

«Депутат җитди сәбәпләрсез алты ай рәттән район Советы утырышларында катнашмаган очракта, район Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла»;

3) 38 статьяда:

1 өлешнең 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

4) 41 статьяда:

6 өлештә «Татарстан Республикасының югары вазыйфаи затын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен) » сүзләренә алмаштырырга;

5) 42 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасының югары вазыйфаи затын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен) » сүзләренә алмаштырырга;

6) 48 статьяның 2 өлешендәге 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

7) 51 статьяда:

2 өлешнең 2.1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

8) 57 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә:

«57 статья Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе»

1. Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе район Советы депутатларын, җирле референдум, чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны район Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, район башлыгы һәм җирле үзидарәнең башка сайланулы вазыйфаи заты әгъзаларын сайлауларны, район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне оештыра.

2. Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе районның җирле үзидарә органнары структурасына керми торган муниципаль орган була.

3. Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон тәртибендә, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән тәртиптә төзелә.

4. Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясенең вәкаләтләре чоры биш ел тәшкил итә.

5. Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш хокукына ия 8 әгъза санында төзелә.

6. Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү район бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

7. Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе вәкаләтләре, аның эшчәнлеге тәртибе һәм гарантияләре федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав белән җайга салына.».